ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Суыксу авыл җирлегенең
Кече Рәс авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

01 ноябрь 2023ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 26 окябрендә 17 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. " 2024 елда балигъ булган һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы? Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Кече Рәс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүчеләрдән алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга:

а) Урам утларын ремонтлауга;

б) Трактор тотуга (ГСМ, запас частьләр, хезмәт хакы);

в) Рөхсәтсез чүплекне бетерүгә;

г) Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү челтәрләрен төзү һәм ремонтлау )су башняларын карап тоту, насос сатып алуга”.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 139 (йөз утыз тугыз) катнашучы кертелгән, 75 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 53,9% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:
халык җыенында 75 (житмеш биш) катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлегенең Кече Рәс авылында халык җыены булып узды, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2024 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлегенең Кече Рәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) Урам утларын ремонтлауга;

б) Трактор тотуга (ГСМ, запас частьләр, хезмәт хакы);

в) Рөхсәтсез чүплекне бетерүгә;

г) Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү челтәрләрен төзү һәм ремонтлау )су башняларын карап тоту, насос сатып алуга".

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.С.Низамиев